«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«29»___ 03____2023 ел** **№368**

Чистай муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
палатасының 2021 елның 28 июнендәге
702 номерлы боерыгы белән расланган
Арендалана торган мөлкәтне милеккә
сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә
ашырганда кече һәм урта эшкуарлык
субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез
мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 2023 елның 23 мартындагы 02-08-02-2023 номерлы муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына протестын карап чыгып, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

1. Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының боерыгы белән расланган Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Җир һәм мөлкәт палатасының 2021 елның 28 июнендәге 702 номерлы боерыгында:

- исемендә, 1 пунктта «күчемсез» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. боерыкның кушымтасында:

- исемендә, 1.1, 2.1 пунктында, 2.4.1, 2.9.1, 2.9.2 пунктының 1 абзацында, 3.5.1 пунктының 3 абзацында, 4 нче кушымтада «күчемсез» сүзен төшереп калдырырга;

- 2.5.1 пунктының 3,4 пунктчалары үз көчләрен югалткан дип танырга;

- 2.6.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5,6 пунктчалар белән тулыландырырга:

«5) түләүләрнең билгеләнгән шартнамәләре нигезендә аренда түләвен кертүне раслый торган документлар - Палата;

6) мөлкәт өчен аренда түләве буенча бурычны түләү турында документлар (штрафлар, пенялар) мондый бурычны түләү турындагы таләптә күрсәтелгән күләмдә (әгәр бу таләп кече яки урта эшкуарлык субъектына җибәрелгән булса) - Палата.

- 2.9.3 пунктында «ләкин кимендә биш ел булырга тиеш түгел» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Ю. Исхакова